



ЧАЯН

СКОРПИОН

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ* МАРТ * 2016 КАЗАН

6



Сергей ТЮНИН

АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Чуровның ни сәбәпле эштән китүе ачыкланды. Трампны хакимияткә китермәс өчен, американлылар кызыктырып, аны үзләренә тартканнар.
- Озакламый президентлыктан китүче Обамага Украинаның Чернигов өлкәсенә губернатор булып килергә тәкъдим ясалган.
- Мария Шарапова, әгәр дә аны мельдоний кулланганы өчен дисквалификацияләмәсәләр, ярышлар вакытында кычкыруыннан ваз кичәчәген белдергән.
- Сыр ясау буенча Дөнья чемпионатында безнең сыр пешерүчеләр брынза медале яулаганнар.
- Кер юу машиналары эшләүчеләр расизмда гаепләнәләр: алар акны карадан аерып юарга кушалар.
- Мәктәпләрдә алтын запасын тулыландыру өчен дәресләрдә алхимия укытуны кертәчәкләр.
- Шәхси кибеткә ревизия ясау нәтиҗәсез тәгәлләнгән: ревизор каршысына янгын сүндерүче һәм СЭС хезмәткәре чыккан.
- Кризис ир белән хатын вазыйфаларын үтәүчеләргә дә кагылган. Бу көннәрдә генә П. исемле гражданинга коллекторлар килгән.
- Бер балалар бакчасында педикулез тапканнар, ә мөдире кашынып та карамый икән, исе дә китми ди.
- Хатын белән ир гаилә гербы уйлап тапканнар – рюмка һәм елан.
- Бер мандатлы сайлау округында ир сайлау буенча сайлаулар үткәреләчәк.
- Автомобильдә йөрүче берәүнең өрүе алкотестны эштән чыгарган.
- Кияү буласы кеше кәләшен макияжсыз күреп, аны судка биргән, ә кәләше аптырап калмаган, моны трусиксыз күреп, үзен судка тарткан.
- Җыештыручы-гастарбайтерның туган ягында Рәсәйдә көрәп акча алуына һич шикләнмиләр.
- Банклар талаучыны тотканнар. Ул "Таланганны тала" девизы буенча талаган.
- Балалар бакчасындагы балалар дәресләрдә ярты ел буе пластилиннан кәҗәләр ясаган. Чөнки аларның тәрбиячеләре бу вакытта аерылышу халәтендә булган.

Илдус АЗИМОВ





ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Соңгы вакытта сәяси оппонентларга торт ыргыту модага керде. Һәм бу Чарли Чаплин рухындагы шаярту дип бирелә. Минемчә, мондый «шаярту» юмордан бик ерак тора...

В. РӘХИМОВА

ТӘТЕШ

– Әлбәттә, бу юмор түгел, – диде Шомбай ага. **– Әгәр торт сәясәтченең йөзендә икән – бу инде сатира...**



Виталий ФЕОКТИСТОВ



АКШ аның рөхсәтеннән башка күрше дәүләткә һөҗүм иткән агрессорны кискен рәвештә гаепләде.

(телевидениедә ток-шоу)

Бу оешмада клиентларга каршы көрәш бүлеге ачканнар диярсең...

Ул – намуслы кеше, аннан бөтен нәрсәне дә көтәргә була...

(хатлардан)

Пенсионерлар игътибарына! Пенсия исәпләүне дәвам итәр өчен исән булуыгыз турында белешмә алып килергә кирәк.

Чәршәмбе көннәрендә җитди мөнәсәбәтләр өчен чибәр, акыллы кыз эзлим.

Стадионга трибуналарны җыештыручы таләп ителә.

(белдерүләр)



Валерий ТАРАСЕНКО

Рәис САФИН

ШАКАЛЛАР СОЛЫ АШАМЫЙ

Ат авырып китте. Хәлен
Шакалларга сөйләде.
Тегеләр тешләр ыржайтып,
Калҗа бүлмәк теләде.

Капладылар мескен атны,
Билгеләделәр хакны.
“Сырхавың хәтәр! – диделәр, –
Яшәвең ике яклы...

Әгәр файдам булсын дисәң,
Безне ит белән сыйла.
Малыңмы, әллә җаныңмы, –
Икенең берен сайла!”

“Үлемтеккә диеп җыйган
Солым бар, өч-дүрт улак...”
“Шакаллар солы ашамый,
Бугазында безнең хак!..”

Виктор ФЁДОРОВ



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Балаларда иң күңелле нәрсә – аларны ясау процессы.

Кунакны күпме ашатсаң да, ул күбрәк эчү ягын карый.

Киләчәк никадәр ераграк булса, шулкадәр матуррак булып күренә.

Адвокатлар ике төрле була: берәүләре законны, икенчеләре судьяны яхшы белә.

Тормыш күңелсез, аның каравы, хезмәт хакы көлеп үләрлек.

Җүләрне үз урынына куяр өчен бераз кысыла төшү җитә.

Даими тырыш хезмәт кенә маймылдан алтынчы разрядлы слесарь ясый ала.

Көзгегә озаграк караган саен, ул Дарвинга ныграк ышана барды...

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)

ЛЬГОТАГА СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛ

Бөек Ватан сугышы ветераннарын без, әлбәттә, истә тотабыз. Тик һәркайчан түгел. Гомумхалык мәхәббәтенең иң зур дулкыны, кагыйдә буларак, май башына туры килә дә ай ахырына таба әкрен генә тына. Ә башка вакытта ветеранны гади пенсионердан аеру кыен. Күкрәгендә орден-медальләр ялтырап торса да, фронтовикларга дары исе иснәмәгән пенсионерлар кебек үк күпсанлы көнкүреш мәсьәләләрен хәл итәргә туры килә.

Сугыш ветераны Равил Хәкимов кебекләрне картаймас җанлы дип атыйлар. Үзенең 88 яшендә ул һаман дәртле һәм эшчән: хәзерге вакытка кадәр Татарстан Республикасының Ветераннар берлегенең социаль-хокук бүлеге мөдире булып эшли.

Шулай берзаман Равил абый үзенең начаррак ишетә башлавын сизә. “Ярый, баш бәласе түгел, – дип уйлап куя фронтовик. – Бу бит Берлинны алу түгел. Үзем бит күптән түгел генә республикада колак аппаратларын льгота буенча алуны берничә тапкыр гадиләштерү турында отчёт язган идем”. Һәм ышанычлы адымнар белән тиешле белешмә алырга юнәлә.

Аппарат алу юлында киртәләр шунда ук барлыкка килә. Сугыш ветераннары госпитале янындагы поликлиникада ЛОР табибы юк икәнлеге ачыклана. Ветеранны яшәү урынындагы поликлиникага җибәрәләр. Аннан Республика клиника хастаханәсенә юллама тоттырып чыгаралар. Кирәкле белгеч – сурдолог (бөтен республикага бердәнбер) шунда эшли икән. Ә чират өч айга сузылган.

Начар ишетүче фронтовикның мөхтәрәм яшьтә булуы турындагы сүзләрен беркем ишетми. Үҗәт ветеран барыбер табиб тарафыннан кабул ителеп, чираттагы кәгазьләрне алу бәхетенә ирешә. Хәзер инде Баш медицина-социаль экспертиза бюросына барырга кирәк икән. Анда Хәкимовны кабул итмиләр – документлар пакеты тулы түгел, имеш. Аның урынында кайберәүләр күптән чигенгән булыр иде, тик фронтовик Хәкимов түгел. Равил абый колак аппараты өчен ахыргача көрәшергә була.

Экспертиза бюросына соңгы, өченче “поход” күңелсез тәмамлана: ул бөтен кирәкле документларын җыеп, шунда барган чакта таеп китеп кабыргасын сындыра. Трвмпунктта ветеранга... льгота буенча корсет алу мөмкинлеге турында хәбәр итәләр. Ләкин башыннан кичкән “льгота газапларын” әле онытырга өлгермәгән карт солдат әдәпле генә баш тарта.

Хәкимовның тиешле аппаратны алырга дип сәфәр чыккан көннән сигез ай үтте. Һәм Равил абый берничә дә карамастан, максатына ирешә. Татарстан буенча социаль страхование фондында аның гаризасын кабул иттеләр һәм кәтәргә куштылар. Колак аппаратлары кайту белән ул үзенә тиешле аппаратны алачак, дип сүз бирделәр. Бу вакыйга кайчан булыр икән, дигән сорауга җилкәләрен генә җыердылар...


Равил абый ветеран пенсиясенә сатып алынган каты корсет киеп, элеккечә эшкә йөри. Һәм шулай ук фронтовиклар тормышындагы катлаулыкларны хәл итәргә ярдәм итә. Мисал өчен, күптән түгел аңа Казаннан 90 яшьлек сугыш ветераны Павел Владимирович Григорьев... колак аппараты алуда ярдәм итүен сорап мөрәҗәгать итте. Хәкимов аның үтенечен кире какмады...

Людмила САФИУЛЛИНА

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Николай ВОРОНЦОВ



Вячеслав БИБИШЕВ







• • •

– Директор штатта зур кыскартулар үткәрәчәк дигән сүзләр йөри.

– Бу безгә кагылмый. Ул хатыны белән ачуланышкан, шуңа күрә аны бөтен туганнарын эштән азат итү белән куркыта.

• • •

– Син ишеттеңме, Англиядә 100 яшь тулганнар королевадан котлау телеграммалары алачак икән.

– Бездә дә шундый гадәт кертергә кирәк. Пенсиягә чыккан көнне президент һәммәбезгә телеграмма җибәрсен һәм Россия почтасы аны йөз яшебез тулганда, мөгаен, китереп җиткерер.

• • •

– Кадерлем, миңа тагын телефон сатып ал әле.

– Ә теге, икенчең кайда соң синең?

– Анысы миңа тун бүләк итәчәк!

• • •

– Мин бүген иртән финанс агымында катнаштым...

– Ниһаять һөнәрең буенча эш таптыңмы әллә?

– Юк, троллейбуста минем аркылы, утырып барган өчен, билетка акча җибәрделәр!

• • •

Беркатлы, юкка-барга ышанучан Жерар Депардье Рәсәйнең паспортына ия булды, ләкин шунысын әйтеп үтәргә кирәк, ул үзенең сыртында ике кредит, алимент һәм ипотека барлыгын, күрәсең, уйлап та карамаган.

• • •

Бер директор икенчесеннән кызыксынып сорый:

– Ничек син үзеңнең кул астында эшләүчеләрне эшкә соңга калмаска өйрәттең?

– Бик җайлы гына: миндә 30 кеше эшли, ә машина урыны егерме генә.

• • •

Белдерү:

“Хөрмәтле фатир хуҗалары, ай ахырына хәтле газ өчен түләвегезне сорыйбыз. Түләмәгән очракта газ вентиляция торбалары аша җибәреләчәк”.

• • •

Хуҗабикәләр игътибарына. Куәте аз булган лампочкалар фатирыгызга түләүне киметеп кенә калмый, алар бүлмәләрегезне чиста һәм җыйнак, ә үзегезне матур, купшы итеп күрсәтәчәк.

Александр АЛЁШИН



Нажия БӘХТИЕВА

ЕЛМАЮЛЫ ЫСУЛ

Елмаю сәламәтлек өчен бик файдалы – галимнәр шулай ди. Хәтта ясалма елмаю да уңай энергиягә ия, имеш. Шуңа күрә Көнбатышта бөтенесе ыржаеп йөридер дә инде!

Мин моны үземдә сынап карарга булдым. Кем белә бит, елмаюга бәхет дигәне дә ябышыр...

Иртә белән үк бу елмаю ысулының ничек эшләвен тикшерергә чыгып киттем. Почтаны тикшердем – анда ЖКХдан яңа түләү кәгазе килгән. Башта үкереп җибәрәсе килде, аннан соң үземне кулга алдым да аларның конторына киттем. Елмаеп сорыйм болардан: мондый бәяләр каян килгән? Ә алар никтер йөгерешеп йөри башлады, шкаф-ишекләр белән шалт-шолт иттеләр дә каядыр качып беттеләр.

Ярый, мәйтәм, алайса поликлиникага кереп чыгыйм әле. Регистратор, гадәттәгечә, кычкыра башлады: "Нинди талоннар, ди, ул, сәгать унынчы киткән!" Ә мин, киң елмаеп, башка белгечләр турында сораштыра башладым. Аның нишләптер коты алынды, чират та никтер тарала башлады... Барысы да ниндидер сәер.

Кибеткә кагылдым, анда тагын да аңлаешсызрак хәл. Мин елмаеп бәяләр һәм товарның саклану срокларын ачыклыйм, ә сатучылар йөгерешә, пышылдаша башлады. Товарны әрҗәләре белән каядыр алып китә башладылар, ә аннан соң бүлекне учётка ябып куйдылар. Ә чыгып киткәндә ике сакчы миңа хәтта честь бирде.

Өйгә кайтып җиттем, подъезд янында күрше хатын утыра. Исәнләштек, сөйләшеп киттек. Ул үтереп ирен мактый, ә мин тыңлыйм. Мин киңрәк елмайган саен, аның кәефе кырыла бара. Хушлашмыйча китеп барды. Нәрсәгә үпкәләде икән?

Шунда аңлап алдым: безнең өчен түгел ул елмаюлар. Алар бөтен кешегә күңелсезлек кенә китерә. Иң яхшысы – искечә яшәү. Тешләрне кысып, яңа үрләргә. Ә елмаю... Әнә, сәхнә йолдызлары, телевидение мәзәкчеләре, депутатлыкка кандидатлар елмайсын. Аларга килешә ул.

Илдус ДИНДАРОВ

СӨЙГӘННЕКЕ СӨЙКЕМЛЕ

Заһитларга кергәч күрәм:
Утыра ике мәче.
Агын беләм, үзенеке,
Карасы шикле мәче...
Шакир абзый зарын сөйли,
Заһит чыккан арада:
– Бусы күршеләрнеке лә,
Үзең шуннан чамала.
Ул малайның ташы кызган...
Тиле кеше әйтмешли,
Песиен иямәштерде дә,
Кызы белән эше пешми.
Чит мәчегә сүз әйттерми,
Ул хәзер "тансык" кунак.
Сөтен-маен сыпырта да,
Өенә кайтып куна.
Нармальнымы,
Үз йортында тычкан тотып,
Бездә йоклап, тәк ятса? –
Ярый ла ул, Заһитыбыз,
Канса-кансов,
Кызны үзенә каратса?!



Эрнест ДЫШАЕВ



• • •

Иван Царевич француз ресторанына керә, ә анда кыздырылган бакалар, пешерелгәннәре, соус белән бирелгәннәре...

– Менә алар бака белән нишлиләр... Ә мин, җүләр, өйләндем!



Александр СЕРГЕЕВ




Валерий ТАРАСЕНКО





Валерий ТАРАСЕНКО



Виталий ДУБИНИН

Валерий АНТОНОВ

«ДВОЙНОЙ СТАНДАРТ»

– Нәрсә соң ул “двойные стандарты”? – дип сорап куйды хатын.

Тагын ниләр уйлап казынуы икән инде моның? Шуңа шикләнебрәк калдым мин моның сүзләреннән. Аның бар эше: сәгатьләр буе телесериалларның эчтәлеген сөйләү, эшендәге хәлләрдән зарлану, күршеләрнең тетмәсен тетү иде... Бер дә көтелмәгәндә, кисәк менә мондый сорау биреп куюы эчне пошыра башлады.

Әллә инде хатын безнең офистагы теге яңа килгән чибәркәй белән чуалуымны сизде микән? Шуны тикшерүе булдымы икән бу шпионлыгы? Кара син аны, еректан казый!.. Имеш, мин өйдә гел: “Син минем бергенәм, күз нурым!” – дип сайрыйм. Ә чынлыкта, яшерен икенче дөньям бар...”

– Син миңе ишетәсеңме соң? – дигән тавышы яңгырады хатынның.

– Әйе, әйе, ишетәм, – дип җавап бирдем, саграк булырга тырышып.

Ә бәлки ул ашханәдә эшләүче Сания турында беләдер? Ул бит миңа һәрвакыт тәлинкәмә ике порция гуляш сала. Әлбәттә, аңа күз кысып йөрүем өчен генә түгел... Гәүдәмнең күләменә карата, һичшиксез, ике генәме, өч порция салырга кирәк әле миңа! Менә шуңа күрә бу очракта двойной стандарт кына җитеп бетми әле, җаныкаем, тройной кирәк! Каян белде икән шуны?!

Күңелгә шом керде. Күз алдыма якын киләчәктәге бәхетсезлегем күренешләре килеп басты: хатын минем белән аерылыша, фатирдан куып чыгара, машинасыз да калам, эшемә барып гауга күтәрә, димәк, мин “беттем” дигән сүз...

Соң булганчы барысын да ачыктан-ачык хатынга сөйләп бирергә кирәк, дигән фикергә килдем. Чын күңелдән дөресен әйтү – аңлашуга китерә... Ике тапкыр үлеп булмый – шулай итәм...

– Мин сиңа әйтергә тиешле... Чөнки син үзең дә бе... – дип, көчәнеп кенә башладым сүземне, хатынга якыная-якыная.

– Син нәрсә мыгырдыйсың? Бернәрсә аңламыйм!

Бераз хәл алганнан соң, яңадан акланууыма керештем:

– Мин син сораган теге двойной...

– Ә-ә, син аның турындамыни?.. Мин аны телевизордан ишеткән идем. Көнбатыш безнең белән двойной стандартлар кулланып эш йөртә. Нәрсә җитми аларга, аңламыйм?!

– Көнбатышкамы? Двойной стандартлар буенчамы? – дип әйткән булдым мин, әле үземә бәхет елмайганга ышанмыйча. – Алар бит бездән көнләшәләр! Бертөсле әйтәләр, бүтәнчә уйлыйлар. Без менә синең белән кебек түгел. Безнең болай: күңелебез ничек уйлый, шуны уртага салып сөйләшәбез. Шулай бит?..

Ризалык белдереп һәм канәгатьләнү хисе белән хатын башын селкеп куйды.

– Җә, ярый, җитте сәясәт турында сөйләшергә, нәрсәгә ул безгә! Кичке аш әзерме?..

Тәмле итеп ашап утырганда, мин яратып кына, хатыныма караштыргалап алдым. Күңелемдә, Көнбатышка карата моңа хәтле булмаган җылы хисләр кайный иде.

Эрнест ДЫШАЕВ



Алексей БУЛАТОВ



Илдар НӘФИЕВ



Владимир ИЖБОЛДИН





КОМФОРТЛЫ ЗОНА

Европадагы иректән мәхрүм итү урыннары югары комфорт белән аерылып тора, дип сөйлиләр. Утыручылар өчен Интернетка тоташтырылган компьютерлы аерым камералар дисеңме, тренажёрлар белән спортзаллар, ашханә өстәлләрендә меню дисеңме... Түбән Каманың 2 нче төзәтү колониясе башлыгы урынбасары Эдуард А. да дөнья тенденцияләреннән калышмаска булган. Колония территориясендә ул карау астындагылар өчен... ресторан ачкан. Ресторанга ришвәт биреп кенә кергәннәр, әлбәттә. Аңа карамастан, аш-су приборлары белән затлы ризыктан авыз итәргә теләүчеләр җитәрлек булган. Тик "ресторатор"ның эшчәнлеге белән тикшерү органнары кызыксына башлаган. Хәзер "зона хуҗасы" урынбасарына безнең зоналардагы комфорт дәрәҗәсенә бәя бирү мөмкинлеге барлыкка килүе мөмкин.

СУДНЫҢ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

Карелиянең Верховный суды җирле "Северные берега" газетасын катлаулы хәлдә калдырды. Газетада аерым МВД хезмәткәрләренең кылган тәртипсезлекләре турында мәкалә басылып чыккан булган. Бу материалда автор ике рус халык мәкале файдаланган: «Закон – что дышло, куда повернешь, туда и вышло» һәм «Законы святы, да законники лихие супостаты» (мәгънәсе: "Закон тәртә кебек, кая борсаң, шунда бара" һәм "Законнары изге, тик закончылары явыз"). Ләкин суд бу мәкальләр Эчке эшләр министрлыгын яманлый дип тапкан һәм редакциягә аларның дөреслеккә туры килмәве турында язып чыгарга тәкъдим иткән. Баш редакторга бер генә юл: газета аша законның тәртә булмавы һәм закончыларның явыз булмаулары турында белдерү ясау кала. Күрәсең, суд халык зирәклеге мисалларын да гамәлдән чыгара ала икән.

ХӘЛ ИТҮ ЮЛЫ

Интернет файдаланучылары арасында Америкада чыга торган The Daily Caller басмасының мәкаләсе зур дулкынлану уятты. Анда Мурманск өлкәсендә рус егетләренең дискотекада җирле кызларга бәйләнгән Якын Көнчыгыштан килгән законсыз мигрантларны "акылга утыртулары" турында сүз бара. Германиядәге Кёльн шәһәрендәге охшаш вакыйгадан аермалы буларак, кырыс төньяк егетләре полиция ярдәменә өмет багламыйча, үз көчләренә таянганнар. Бу вакыйга чынлап та булгандырмы, монысы билгеле түгел. Тик европалыларның күбесе илдәшләребезнең бу кыю эшен яклап чыккан. Ә кайберәүләре моны чакырылмаган кунакларның тәртип бозу проблемасын хәл итү юлы итеп кабул иткәннәр.

Никифор ТУКМАЧЁВ

НАРДУГАНДА

Шәһәрдә йөргән Шүрәле
Кинәт егылды таеп.
Егет дисәң – мөгезе бар,
Ир дисәң... никтер аек!

САТЫЛА

Акыл сатам, кемгә кирәк,
Кил базарга, кибеткә!
Шимбә якшәмбе яшьләргә
Ун процент "скидка".

• • •

Ике яшьлек буаз тана
Сатам, дип, язган кемдер.
Балигъ булмаган ул тана
Юньле нәрсә түгелдер.

• • •


Китереп тә бирәмен, ди,
Берәү сата каз-үрдәк.
Китереп бирүчеләр ул
Безнең шәһәрдә меңләп.

• • •

Рекламаларга ышанып,
Алданма берчакны да.
Яхшы кәләш, дип димлиләр
Убырлы карчыкны да.

Иза СӘЙДӘШЕВА





Игорь КИЙКО

Искәндәр БОРҺАНОВ

ТЕЛЕФОН АША ТАНЫШУ

– Сәлам, – диде кулына трубка тоткан озын буйлы чибәр егет һәм җилдә тузгып барган озын бөдрә чәчле кызны куып җитте.

– Сәлам, – диде кыз башын да бормыйча, әллә аңа, әллә трубкага.

– Хәлләр ничек? – дип сорады егет каядыр еракка карап.

– Бүген өч пар булды, – диде кыз, – ә аннан соң әле эшкә барасы бар. Ә синең ничек?

– Минем нәрсә булсын инде? – диде егет трубкага. – һәрвакыттагыча, хәзер эштән кайтып барам, аннан соң тренировкага. Ә син кич белән ничек?

– Юк, кич белән беркая да йөрмим, урам тулы маньяклар. Менә хәзер дә берсе бәйләнергә маташа, – ул чибәр егеткә таба борылды. – Нәрсә тагылдың, юлыңда бул һәм бәйләнмә, алайса хәзер дусларны чакырам...

– Мин бәйләнмим, тыныч кына барам, телефоннан сөйләшәм, – диде егет гаҗәпләнеп, аннан соң бераз читкә борылды һәм кычкырып җибәрде. – Мин беркемгә дә бәйләнмим, ниндидер җүләр кызый мине үзенә бәйләнә дип уйлаган...

– Мин җүләр кызый түгел, – диде кыз, – мин телефоннан сөйләшәм, һәм үз юлым белән барам, ә син мине инде ун минут эзәрлекләп киләсең...

– Юк, мин телефоннан сөйләшәм, ә син кинәт кенә миңа ташландың, – диде егет, кызга таба борылып.

– Ә, син... телефоннан, – дип каш сикертте кыз. – Ә мин сине маньяк дип торам, – диде һәм трубкасына борылды. – Барысы да тәртиптә, мин... ялгышканмын...

– Нинди маньяк? Ә синең исемең ничек? – дип сорады егет.


– Минеке 92178456357, ә синең? – диде кыз һәм егеткә җылы итеп карап алды.

Ә минеке 23167456897, – диде егет. – Мин хәзер бик ашыгам, соңрак сөйләшербез әле...

Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



МИН нәрсәм белән ким?

Дмитрий ФИЛИППОВ

Хәзер балаларны сабый чактан ук төрле түгәрәкләргә язалар. Музыка, чит телләр, спорт түгәрәкләре... Дөнья хәлен белеп булмый, тормышта кирәк булып куюы бар бит.

Берзаман бер түтәйгә исерек әзмәвер бәйләнә башлаган. Түтәй аны кулыннан эләктереп алган да җилкә аша әйләндереп салган – теге ярты сәгать һушына килә алмыйча яткан. Түтәй бала чагында самбо түгәрәгенә йөргән, күрәсең. Кирәге чыккан бит...

Шулай бер Мәдәният йортына үзешчәннәр концертына бардым. Ә сәхнәдә җирле полиция нәчәлниге гитарада уйный, Себер лагерьлары, зур сроклар турында җан өзгеч романс җырлый. Ишегалды түгәрәгендә блатной аккордлар өйрәнгәне күренеп тора...

Шәһәрдә бадминтон буенча ярышлар булды. Анда безнең мэр да катнашты.

Воланны бар көченә бәреп җибәрде, ә ул – соңгы рәттә утырган бер тамашачының нәкъ маңгаена. Бичара гомере буе тотлыгудан интеккән, ә монда тотлыгуы бетте. “Рәхмәт! – диде ул көр тавыш белән. – Минем сәламәтлегем турында кайгыртканыгыз өчен”.

Бала чагында мэр җиңел атлетика түгәрәгенә йөргән икән. Кулындагы көч шуннан калган да инде. Бу очрактан соң шәһәрдә клиника ачылды – тотлыгуны бадминтонотерапия белән дәвалау буенча...

Эштән соң өйгә кайтып керәм. Телевизордан губернатор рояльдә бер бармагы белән “Галиябану”ны уйнап утыра. Җаннарга үтәрлек итеп... Драмтүгәрәктә тәрбияләнеп чыкканы әллә каян күренеп тора. Чын артист...

Хатыным карап торды-торды да, түзмәде:

– Нигә миңа шундый булдыксыз ир эләкте икән? Башкалар әнә ниләр кыланалар! Ә син...

Рәнҗетте мине хатын.

– Ә исеңдәме, – дим, – мин мәктәптә «Яшь гайдарчы» түгәрәге алып барган идем? Беренче сыйныф укучыларына реформалар һәм игелекле Ельцин бабай турында әкиятләр сөйләп йөргән идем. Мин хәзер дә сәяси яктан төшеп калганнардан түгел!

– Соң, бар! – ди хатын.

– Кая? – дип сорадым мин, аңламыйча.

– Депутатлыкка! Зур сәясәткә атла! Моңа хәзер өстән бернинди дә рөхсәт кирәкми, диләр.

Ә нәрсә? Бәлки чынлап та кузгалыргадыр? Башкалар әнә нәрсәләр кылана! Ә мин нәрсәм белән ким...

Рөстәм ЗАРИПОВ

ЛАУРЕАТ ЗАРЫ

Шигъри канатлы атка атланып
Чабу рәхәт, селтәп кабык кылыч;
Тукай бүләген алышкан дуслар
Таләп итә башлый бер көн бурыч...
Син миңа – мин сиңа кагыйдәсе
Кемгә генә тәэмин итми уңыш...



Чаян шифаханәсе



• • •

Психиатрия хастаханәсендә табиб кроссворд чишеп утыра:

– Тә-әк... Наполеон туган утрау...

Пациентына мөрәҗәгать итеп:

– Әй, тиле, син кайда тудың?

Галим ӘНӘСОВ

ТЕШ СУЫРУЧЫ ҺӘМ САЛЫМ ИНСПЕКТОРЫ

Теш дәвалау кәнәфиенә сеңеп утырган бухгалтер Кылычтешев, табиб белән медсестраның колагына кергән сүзләреннән соң, чыгып качар хәлгә килгән иде.

– Төп эшемнән тыш тагын бер җирдә ярты ставкага урнашырга тәкъдим иттеләр – моргта. Ике мәеттән соң өченчесендә дежур торышлы. Мин ризалык бирдем, – дип мактанып куйды табиб.

– Яхшы эш... Берәү дә йокыңны бүлеп йөрмәс, – диде, аның сүзләрен җөпләп медсестра.

Теш табибы кулларын юды да Кылычтешев янына килде:

– Авызыңны ыграк ач... ыграк, тагын да ыграк!.. Калтыранма әле шулхәтле. Тирләмәгез дә ул чаклы, тирегездән анализ алмыйбыз.

Табиб барлык эш коралларын бухгалтерның авызына тыкты да тешен шакылдата башлады. Теш чокырларында яшереп куелган хәзинәләре юк микән дип уйлый, ахрысы. Суккан саен Кылычтешев авыртудан "ай, ай" дип кычкыра торды.

– Аңлашылды, минем өчен бар да ачык – пародонтоз. Дәвалаячакбыз, – дип авызын шапылдатты, әйтерсең лә штопор белән шешә ачты.

– Кирәкле дарулар бетте. Китерергә вәгъдә биргәннәр иде. Бер атнадан соң булыр, – диде медсестра, авыр сулаган булып.

– Ә гадәти булмаган медицина юлы белән? – дип Кылычтешев аптыраганнан әйтеп куйды.

– Күп сөйләшүдән бәя кимеми – теш дәвалау хезмәте хәзер кыйбат. Суырып ташлау җайлырак.

– Укол салмыйчамы? – дип куркуын яшермичә сорады бухгалтер.

– Әгәр дә үзегез белән алып килмәгән булсагыз – сездән биш мең, – диде медсестра.

– Димәк, уколыгыз бар?

– Бар, бар.

...Теш дәвалау кабинетыннан чыгып киткәнче Кылычтешев үзенең портфелендә озак актарынды. Алып ташлаган теш урыны үтереп сызлый. Ниһаять портфеленнән бер кәгазь тартып чыгарды да теш табибына сузды.

– Нәрсә бу? – диде теге, гаҗәпләнеп.

– Салым декларациясе бланкы. Менә шунда барлык керемнәрегезне кертеп языгыз. Моргта эшләвегезне дә онытмагыз. Мин – салым инспекторы. Сезнең кебек ярты ставкага эшләп йөрим.



Виталий ФЕОКТИСТОВ

Александр АЛЁШИН



Александр КОСМЫЛИН





КОММУНАЛЬ КОРЫЛЫК

Кадерле Чаян! Әйтүләренә караганда, тиздән су кара алтын бәясенә җитәчәк икән. Без, Званка авылында яшәүчеләр, киләчәкне юрарга яратмыйбыз. Бүгенге көндә бездә су бетү куркынычы беренче планда тора. Атналар буе су күргәнебез юк. Суүткәргеч торбалары тәмам череп беткәнлектән, әллә ничә җирдән су агып ята. Төзекләндерү эшләренә акча каралмаган. Бүгенгесе көндә су белән тәэмин итү системасының хуҗасы да юк. Элеккеге хуҗа – Кощаков нәселле ат заводының суүткәргечне карап тотарлык мөмкинлеге юк, ә авыл советына тапшыру мәшәкатьләре бик озакка сузылды.

Коммуналь корылык проблемасын түрәләр ишетеп кенә түгел, күреп тә белә. Чөнки районның беренче вәкиле күптән түгел бездә яши башлады. Әйтүләренә караганда, йортына яңа суүткәргеч тә үткәргәннәр икән. Суга тилмерməүләренә шатбыз, әлбәттә, проблемалы гомум мәйданда суүткәргечнең һаман аяныч хәлдә калуы безне бик борчый...

Званка бистәсендә яшәүчеләр

ПИТРӘЧ РАЙОНЫ

ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕ

Соңгы вакытта коллекторлар агентлыгы башбаштаклыкларын сөйләп бетерә торган түгел... Халыкта “вышибала”лар дип йөртелгән әлеге агентлык хезмәткәрләренә эләксәң, эш харап. Аларның законы үзләре белән. Коллекторлар акчаны кире кайтару өчен иң рәхимсез чарадан да баш тартмый: йортына ут төртү белән куркытумы яисә янаулы шалтыратулар белән инфарктка җиткерүләрне әйтәсеңме...

Кредит алганым булмагач, әлеге михнәт мине урап узар дигән идем, юк икән шул! Соңгы вакытларда янаулы төнге шалтыратулар белән теңкәмне корыттылар. Ачулы ир тавышы банкка әҗәтемне кайтаруны яный башлады.

Нинди әҗәт, кайчан алганмын? Аптырап, банкка барып белештем. Исем-акылым китте... бурычка алган күршемнең ышанычлы әһеле булганмын икән. Югыйсә мин бернинди ризалык та бирмәдем, бер кәгазьгә дә имзамны куймаган идем бит...

Күршем кредит алганда минем телефонны биргән булып чыкты. Кемдер шалтыратып күршеңне беләсеңме дигән сорауга беләм дигән җавабым ышанычлы әһел булырга җиткән икән.

Ничек минем телефон коллекторлар кулына эләккән, прокуратурага шикаять язам, судка бирәм дип янагач, банкирлар эшне җайлыйбыз, дип ышандырды. Дөрес, әлегә төнге шалтыратулар белән борчымыйлар. Кем белә, күпмегә җитәр?..

Н. САДЫЙКОВА

ЧАЛЛЫ



Рәдиф ГАТАУЛЛИН

ГАИЛӘ ӘДӘБИЯТЫ

И, без нинди матур идек! –
Күбәләктәй җиңел йөрдек
очып, сөю тирәсендә;
гашыйк син дә, гашыйк мин дә...
Идеалларны таптык, гүя –
булганбыз Поэзия...

Ахыр – юллар бергә булмыш.
Җиңел генә булмый тормыш:
Үпкәләштек бераз гына,
Үртәштек тә аз-маз гына;
җилләр тынса, дулкын шыма,
эзе калса, кала азга...
Ну, болары инде – Проза.

Күңел – шайтан. Бер-береңә
Көнлисең дә – Комедия!
Аңлашканда – тулы Драма;
Характерлар туры килми,
ә жанрлар ерак йөрми –
булу мөмкин Трагедия!

Катлаулы соң әдәбият! –
Безгә дә бертөрлелек ят:
Бер-беребезне өйрәнәбез;
өйрәтәбез;
хаталарны әйтеп, чәнчеп.
...Гаиләне ныгытырга да
Кирәк икән шул ук Тәнкыйть!

ЙОКЫСЫЗ ТӨН

Буран...
Авылымнан китә алмый
ятам...

Р. Миңнуллин

Буран йөрде Сөн буенда,
авылда,
Тәрәзәмә кар куллары
Кагыла...
Бер юл яза алмаган моңсыз
Чагымда
кешнәү тавышы ишеттем мин
урамда,
Әллә Пегас калган бүген
Буранда?
Әллә аранын ватып ул
Чыкканмы?
Күктә ай күренми – шуннан
Куркамы?
Кешнәү тынды.
Ни өркетте
Пегасны?
...Кем сызгыра?
Суймасмы
Урлап ул аны?
Атның ал каныны тышта?
...Таң атты.

Әнкәй торып бик иртәдән
Мич якты.
Өшәнгәндер, алып керик
Пегасны!

(1965–1978)



Леонид ЕЛЬКОВИЧ, «Чаян» № 17, 1962



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 5, 1974

– Гангстерлар бу бичараның күз алдында бөтен бензинын суыртып алганнар!

Антон **МАКУНИ**

Йөреп кайттык...

Күптән түгел хатыным әйтә:

– Күңелсез яшибез. Кинога барып кайтасы инде әллә...

Ә мин:

– Нинди кино?! Төнге сәгать икедә!

– Алайса, бәлки, ничек әле ул... төнге клубкадыр?

Мин аңа:

– Нинди клуб, ди, ул сиңа? Үзеңә кара! Анда бит бала-чага, үсмерләр!

– Ә циркка барсак ничек? – ди хатыным.

Ә мин:

– Нинди цирк ул тагын? Әгәр цирк кирәк булган икән, телевизордан Малаховны кара! Көлә-көлә эчең катып бетәр.

Хатын үзенекен тукый:

– Утыра алмыйм мин өйдә! Өйдә мин картаям. Барыйк инде берәр җиргә!

Урамга чыктык. Дөм караңгы. Ни дисәң дә, шәһәр чите бит. Хатын миңа:

– Әйдә, кешеләр булган берәр җиргә барыйк.

Мин аңа:

Әнә кешеләр. Күрәсеңме, дүртәүләшеп “Ока”ны йөк машинасына күтәрергә маташалар.

Хатын колакка пышылдый:

– Бу кешеләр түгел, караклар!

Алар да безне күреп алдылар, кычкыралар:

– Әй, бәлки, ярдәм итәрсез?

Хатын белән карашып алдык та икенче якка элдерттек.

Ераграк киткәч, хатын тагын:

– Әйдә инде, кешеләр янына! Берәр машина туктат!

Мин ярты сәгать буе кул болгап тордым, берсе дә тукталмады. Бер сәгатьләп көткәннән соң берсе туктады. Анысы да мин юлга аркылы ятканга күрә генә. Йөртүче сорый:

– Сезгә кая?

Мин әйтәм:

– Кешеләр булган җиргә алып барыгыз!

Йөртүче:

– Мин андый урынның кайда икәнен белмим шул... Бандитлар, алкашлар, бомжларның кайда җыелганын беләм... Ә менә кешеләр турында күптән ишеткәнем юк.

Кулын болгады да китеп барды. Ә без өйгә кайтып киттек.

Кайтып җиткәч, хатын:

– Менә, йөреп кайттык та...

– Ярый, – дим мин, – әйдә иртәгә урманга барабыз. Анда кешеләр юк, әлбәттә – агачлар гына, аның каравы, бандитлар юк, беркем дә таламас... Һичьюгында анысы да ярап торыр!!!



Игорь **КИЙКО**



Илдар **НӘФИЕВ**



ЧуАр пресса

КАНАТЛЫ ӘҢГӘМӘДӘШ

Кострома өлкәсенең Нерехта шәһәрендә яшәүче бер хатын, командировкадан кайткач, яраткан тутый кошының юклыгын сизеп ала. Кошны читлеге белән бергә урлаганнар. Шиге спиртлы эчемлекләр яратучы күршесенә төшә. Полицейскийлар югалган кошны анда тапканнар. Үзен акларга теләп, күршесе, урлауга барганын дусларча сөйләшергә кеше булмау белән аңлаткан.

КҮҢЕЛЛЕ СӨТ САТУЧЫЛАР

Мәскәү астында сөт фермасы тотучылар Станислав һәм Владислав биш ел буе товар знакларын регистрацияләргә тырышканнар. Ничә ел рәттән абыйлыэнеле Чебурашкиннарның үтенечләрен кире какканнар. Бик күп суд тикшерүләре фермерларның Чебурашка белән берничдә уртаклыклары юк икәнен исбат иткән. Алар “Братья Чебурашкины” бренды астында сөт продуктлары җитештерә алалар.

АВЫР ПАР БЕЛӘН

Талауда гаепләнүче Азатбек Алымкуловны Бишкек судының кулга алынган кешеләр утыра торган бүлмәгә япканнар.

Тик ул сакчылар белән бик тиз уртак тел тапкан, һәм аларны үзенең өенә чакырган. Анда алар әйбәтләп эчкәннәр һәм мунчага киткәннәр, аннан гаепләнүче форточкадан качкан. Вакыйга Азатбек һәм аның яңа дусларының тикшерү изоляторы камерасында очрашуы белән тәмамланган.




Марко КОНЕЛЛИ (Италия)






Фил БЕНЧЛИ (АКШ)



Генрих БЮТНЕР (Германия)



ГИ и РОДД (Бельгия)



Марк ПАРИЗИ (Франция)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Психоневролог бүлмәсе ишегендә язу:

“Кабул итүне көтеп торган авыруларга чирләре турында берберсе белән уртаклашырга киңәш итмибез – бу диагноз куюны кыенлаштыра”.

• • •

Зират каравылчысы конторага килә һәм расчет сорый.

– Нәрсә булды?

– Хәлем калмады. Көннәр буе зират буйлап укып йөрим: “Монда тынган...”, “Монда ята...”, “Монда йоклый...” – дигән язулар. Бер мин генә эшлим!

• • •

Блондинка аш-су осталары телешоуында:

– Ә хәзер мин сезне ничек итеп фрикаделькалар белән бик тәмле аш пешерергә өйрәтәм. Иң башта пилмәнне кабыгыннан арындырырга кирәк...

• • •

– Доктор, минем белән нәрсә?

– Ә сезнең үзегез белән акчагыз күпме?

• • •

Ире, Тимур исемле кәҗә турында тапшыру карагач:

– Кадерлем, син беләсеңме, кәҗәләр ничә ел яши?

– Белмим шул, ә нәрсә, син үзеңне начар хис итәсеңме әллә?

• • •

Үзеңнең кеше сокланырлык гүзәл булуыңа беркайчан да шикләнмә. Шуны исеңдә тот: үлчәүләр алдый, кешеләр көнләшә, ә көзгеләр, гомумән, кәкре!

• • •

– Улым, син кайчан математикадан “икеле“ңне төзәтәсең?

– Белмим, әнием! Укытучы журналны кулыннан беркайчан да төшерми бит!



ЧАЯН (СКОРПИОН)
САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su
16+
Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Юныс ЗӨБӘЕРОВ

ОЧРАКЛЫЛАР ЙОМГАГЫ

Башта Латыйп абзый әле танкистлар, әле шахтерлар көне, әле әллә кемнәр көне дип эчә иде. Заманалар үзгәрә. Замана гына түгел, барлык нәрсә үзгәрә. Вакытка каршы бернәрсә тора алмый.

Латыйп абзый, тора-бара, бер сәбәпсез дә сала башлады. Эшләр болайга киткәч, хатыны: "Исерекбаш, бу эшең сантыйлар йортына эләгү белән бетәр бер көнне, горячка булыр әле", – дип әйтә иде, эшнең ахыры алай бетмәде. Күрәзәлек сәләте юк икән Асма апаның. Эшләрнең ни белән тәмамланачагын сирәк кеше белә шул. Дөрес, получканы ресторанда калдырып чыксаң, ай буена каты-коты-да торачагың кемгә дә ачык. Шулай да алдан белүчеләр сирәк туа.

Эшләр болай йомгакланды. Латыйп абзый дөм исерек килеш "Жигули"ендә авыл очында яңа гына утыртkan баганага бәрелеп, имгәнеп, инвалидлар креслосына утырды. Кеше күзенә карап яшәү бит инде. Шулай көн итәргә калды мескенгә. Ул авыл исеме язылган баганаңы да аның бәрелүенә бер көн элек кенә утыртканнар иде. Котлады ул шулай яңалыкны.

Беркөн хәлен белергә кердем. Дус ук булмасак та, авылдашлар бит әле без. Андый хәлгә калган кешегә нәрсә әйтәсең инде, уйланып тордым да:

– Язмышлардан узмыш юк шул, – дим. – Язмышыңа язган булса, күрәсең. Син күрәчәкне бүтән бер кеше күрми. Башыңны ташка ор, язмыштан узып булмый. Алишер Навои дә әйткән бит: "Язмыш көчлерәк".

– Нинди язмыш турында сөйлисең? Бернинди язмыш юк, – дип җавап бирде Латыйп абзый миңа кырыс кына.

Гаҗәпләнеп киттем аның сүзенә. Сорыйм, инвалид креслосына башны ымлап:

– Үзең гаепле дисеңме бу хәлгә?

– Нишләп алай дим ди. Минем тырнак очы чаклы да гаебем юк, – ди бу.

– Алай булгач, ни эшләп бу хәлләргә калдың?

– Очраклылык, – дип җавап бирә Латыйп абзый. – Монда берничә очрак бергә килеп бер йомгакка буталды. Шулар аркасында мин шулай гомер итәргә мәҗбүр дә инде. Очраклылык дөнья белән идарә итә. Очраклылык. Чын галиҗәнап!

– Нинди очраклыклар? – дип сорыйм.

– Ачык түгелмени? – дип җаваплый Латыйп абзый. – Уйлый белә торган кеше өчен ачык нәрсә бит. Беренче очраклылык. Безнең авыл өч йөз ел тора. Шул гомер авыл исеме язган баганасыз торды. Шайтан алгырлары, именно шушы елны шул баганаңы куярга булдылар. Нәрсәгә кирәк иде ул багана? Уйлап кара. Нык ялгыштылар ул баганаңы утыртып. Беренче очраклылык булдымы? Булды!

Икенче очраклылык. Ул баганаңы июнь аенда утыртырга булганнар. Июль аена калдырсалар, була идеме бу хәл? Гомердә дә булмый иде. Шайтанның икенче бүләге. Июнь аенда ашыгып утырттылар. Аек фикер йөртә белүчегә бу – ачык мәсьәлә.

Өченче очраклылык. Шул баганаңы биш метр алгарак яисә биш метр арткарак утыртсалар, була идеме мондый вакыйга? Аналарын биш тиенгә сатыйм, именно шул урынга утыртканнар. Әзрәк уйласалар, мин ду иттереп яши идем әле. Гомердә дә булмый иде мондый хәлләр.

Шулай, дустым, әнә шул очраклылыклар барысы бергә буталып, йомгак ясап, мине шушы көнгә калдырдылар да инде. Ә син язмыш дисең. Юкка-барга ышанган, җиңел акыллы кешеләр сүзен сөйлисең бит. Хәзерге заман кешесе булырга кирәк, борынгы надан бабайлар сүзенә ышанмаска. Фән бит хәзер ничек алга китте. Космосны айкыйлар бит кораблар. Ә син үткән гасыр кешесе кебек, язмыш, дисең.

Ә мин аңа:

– Синең янга хәл белергә керүем дә очраклылыкмы? – дип көтелмәгән сорау бирдем.

Ул аптырап калмады:

– Хәл белешкән булып йөрүең махсус визит... Бар әле бер ярты алып кайт! Ешрак очрашу очраклылыкларын ныгытыйк! – диде.

Әйе, ул үзенең принциплары буенча яши, ә мин гомер буе сәрхуш дусларыма аракы ташуны, язмышым дип чутлап, менә тагын кибеткә йөгерәм.




Виктор ФЁДОРОВ

Уйна да, уйла да!

Чаянворд

КОМПОЗИТОР ЗАҺИТ
"... КЫЗ"
"... ДИҢГЕЗ" (Т. ГЫЙЗЗӘТ)
"ЯУ БАТЫРЫ ...ГӘ, ...ГӘ КӨРӘШ ДӘРТЕ БИРГӘН ДИҢГЕЗ..."
СПОРТ ЯРЫШЫ
УЛ ХӨРМӘТКӘ ... КИЧӘ
ТАМӘТ, СОЛТАНЫ
АЛИ ИОРТТА МӨҺ КАРШЫНДА КЫЯ ЯТАК
"ТАГЫН ХУШ ... БӘРКИ СИРЕНЬНӘР"
ОСТА ОЧУЧЫ
"... КАДЫЙМ ТҮШЛӘРЕҢӘ"
"ЧҮП ӨСТЕНӘ (-3)..."
ШАГЫЙРЬ, ЯЗУЧЫ САМАТ ...
СҮНМӘС (-1)...
...ТЕХНОЛОГИЯЛӘР
КОМПОЗИТОР ...ДАУТОВ
ПИСТОЛЕТ
"...-СОК БӘЕТЕ"
"...ГЕНӘ ИДЕЛ ДУЛКЫНЫНДА АЙ ТИБРӘЛӘ, КОЯШ ЧАЙКАЛА"
АТТАН ...ДА ТУА, КОЛА ДА ТУА
КАМА КУШЫЛДЫГЫ
"...(-1) ХӘЗЕР АРАБЫЗ..."
ШАГЫЙРЬ ...ФӘЙЗУЛЛИН
ЯЛА, ДОНОС (-1)
0,4 гектар
СТЕНА ЛАМПАСЫ
ХӘРБИ МАШИНА
РӘССАМ МӘХМҮТ ...
"...КАЕН"
САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
УКРАИНАДАГЫ ШӘҺӘР
1000 МИЛЛИМЕТР
ШАГЫЙРЬ ШӘФИГУЛЛИН
ШВЕЙЦАРИЯНЕҢ СӘЯСИ ҮЗӘГЕ
ИДӘН АСТЫ (-1)
"...СИТСЫ КҮЛМӘГЕМНЕ БЕР ГЕНӘ КИГӘН ИДЕМ"
...АЛЫШУ
"БӨДРӘ..."
"ТИК ИКӘҮ БЕЗ — ...ДА МИН" (ТУКАЙ)

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Аякның чәнчә бармагы ни өчен кирәк?

2. Кешенең киеме тәсенә йогынты ясыймы?

3. Ике мең сум акчага кая барырга була?

4. Нәрсә ул штраф һәм нәрсә ул налог?

5. Песиләрнең яраткан йолдызнамә билгесе?

6. Нәрсә ул гражданлык никахы?

7. Ир кешене нәрсәдер эшләтергә мәҗбүр итүнең иң яхшы ысулы?

ҖАВАПЛАР

1. Өйдәге барлык җиһазлар үз урыннарында урнаштырылганлыкны төгәл ачыклау өчен. 2. Ясый, әгәр дә джинсы чалбарын базардан сатып алган булса. 3. Ашанга. 4. Штраф – кемнәрдер дөрес эшләнмәгәнлектән алынган налог. Налог – барысы да дөрес эшләгәнлектән салынган штраф. 5. Балык. 6. Хатын-кыз үзен кияүдә дип уйлап йөрүе, ә ир-атның үзен ирекле итеп хис итү очрагы. 7. Аңа бу эшне үтәүне булдыра алмаячагын искәртү.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 4 нче санында басылган чаянвордның тикшеру сүзләре – **«ХАФИЗӘЛӘМ ИРКӘМ», «КЫР КАЗЫ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. ГАДЕЛШИН (Арча р-ны, Айван ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Айван авылыннан
Ринат ГАДЕЛШИН!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Вячеслав ШИЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор БОГОРАД



Иван АНЧУКОВ



